**АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш,
проспект Ленина,
дом 58, тел.3-44-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423740, Актаныш авылы,
Ленин проспекты,
58 нче йорт. Тел.3-44-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27.06.2025 ел** **№ 15**

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында" 16.03.2020 ел 6 нче номерлы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Актаныш районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 2025 елның 18 июнендәге 02-08-02-2025/Прдп198-25-20920005 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында» 16.03.2020 ел, 6 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Тәртипнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Аналитик белешмә кергән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүматны (булган очракта) үз эченә ала.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш авыл башкарма
комитеты җитәкчесе К.Н.Әхмәтгалиев